ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

27.06.2019 | № 1017

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 нчы елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» гы 2019 нчы елның 4 нче февралендәге 117 санлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 31 мартындагы 191 номерлы карары нигезендә һәм программага үзгәрешләр кертү кирәклеге белән бәйле рәвештә Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты:

КАРАР БИРӘ:

1.Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2019 нчы елда Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында» гы 2019 нчы елның 4 нче февралендәге 117 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. карарның 13.2 пунктында 14 967 800 (ундүрт миллион тугыз йөз алтмыш җиде мең сиксән йөз) сумм сүзләрен 14 989 900 (ундүрт миллион тугыз йөз сиксән мең тугыз йөз) сум сүзләренә алмаштырырга.

1.2. карарның 18.2 пунктындагы Россия Сәламәтлек саклау Министрлыгының «Сәламәтләндерү һәм оешкан ял вакытында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2012 елның 16 апрелендәге 363н номерлы боерыгы белән» сүзләрен, Россия Сәламәтлек саклау Министрлыгының «Сәламәтләндерү һәм оештырылган ял вакытында балигъ булмаганнарга медицина ярдәме күрсәтү тәртибен раслау турында» 2018 елның 13 июнендәге 327н номерлы боерыгы сүзләренә алмаштырырга.

1.3. 2019 нчы елга Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының балалар һәм яшьләр ялы муниципаль программасын яңа редакциядә бәян итәргә (1 нче кушымта).

1.4. 2019 нчы елның 4 нче февралендәге 117 санлы карарына 3 нче кушымта булган, балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (2 нче кушымта).

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыгарга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Н. Рыбаковага йөкләргә.

Җитәкче Р.С. Хәйруллин